**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге Советы**

Чалпы авылы № 152 «01» август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советы 18.06.2018 ел №104 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында
(11.10.2018 № 122, 19.03.2019 №137 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 ел 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 12.05.2003 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карау максатларында, Азнакай шәһәр прокуратурасының «Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы закон бозуларны бетерү турында» 21.06.2019 ел №02-08-03/704-27-2019 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советы 18.06.2018 ел №104 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Нигезләмәгә (11.10.2018 № 122, от 19.03.2019 №137 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирелмәгән очракта, алга таба төзәтелде, граждан яңадан тиешле җирле үзидарә органына яисә тиешле вазыйфаи затка мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.».

1.2. 2.13 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Аерым очракларда, шулай ук ФЗ 10 статьясындагы 2 өлешендә каралган гарызнамәне җибәргән очракта, җирле үзидарә органы җитәкчесе,

вазыйфаи зат яисә ул затка мөрәҗәгатьне карау срогын 30 көннән дә артмаганга кадәр озайтырга хокуклы, мөрәҗәгать җибәргән гражданны карау срогын озайту турында хәбәр итеп.».

1.3. 4.4.пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәп тулыландырырга:

«Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен билгеләнгән тәртиптә шәхси җаваплылык тоталар.».

1.4. 5.2.пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында, органнар һәм вазыйфаи затлар ел йомгаклары буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерергә һәм анализларга бурычлы. Анализда кергән, яңадан тапшырылган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ формасындагы мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм шәхси күчмә кабул итү, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат булырга тиеш.

Әлеге анализ буенча хисап Азнакай муниципаль районының Интернет-мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырыла http://aznakayevo.tatar.ru.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында : http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Мөхәмәтшин